**МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Республиканский конкурс профессионального мастерства работников сферы воспитания и дополнительного образования «Воспитать человека»

Номинация «Воспитание классного коллектива»

# ПАСПОРТ ВОСПИТАТЕЛЬНОЙ ПРАКТИКИ

**Проект Школьная газета – «Гимназия сулышы»**

*(Посвящается светлой памяти великого драматурга и писателя Туфана Миннуллина)*

**Автор воспитательной практики:**
Гарифуллина Эльмира Масхутовна, учитель
татарского языка и литературы,
классный руководитель 8б класса
МБОУ «Карадуванская гимназия
имени Баки Зиятдинова»

**2024г.**

| | |
|---|---|
| Полное название воспитательной практики | Проект Школьная газета – «Гимназия сулышы» Посвящается светлой памяти великого драматурга и писателя Туфана Миннуллина |
| ФИО, должность и наименование образовательной организации авторов воспитательной практики | Гарифуллина Эльмира Масхутовна, учитель татарского языка и литературы классный руководительМБОУ Карадуванская гимназия |
| Аннотация воспитательной практики | Школьная газета – является мощным средством воспитания, сплочения и образования молодежи, средство воспитания нравственности, патриотизма, формирования активной гражданской позиции, а также средство повышения интереса к учёбе. 10 лет существует в нашем образовательном учреждении школьная газета «Гимназия сулышы». Она – плод совместных усилий неравнодушного, активного, деятельного и творческого коллектива единомышленников из числа детей, педагогов, администрации школы.<br>Она позволяет охватить достаточно широкий круг учащихся, различных и по возрасту, и по интересам, и по социальному положению, способствует сплоченности детей, совершенствованию межличностных отношений через умение считаться с мнением, интересами и желаниями своих товарищей.<br>Школьная газета играет большую роль в жизни подростков, работающих над ней. Она способствует взрослению ребят, их воспитанию. Ещё одно качеством, которое «взращивает» газета-ответственность. Ведь работа в команде - дело серьёзное и трудное. Каждый берётся за ту работу, которая ему по плечу.<br>Работая над созданием школьной газета, устанавливаютя более тесные микросоциальные связи внутри школы. Участие учащихся в школьной редколлегии поддерживает их индивидуальное развитие, так как помогает организовать себя, выразить свои мысли, распространить их среди |

| | |
|---|---|
| | других людей, помогает лучше познать себя, открыть мир. Кроме того, подобная практика оказывает влияние на выбор профессии. Школьники смело шагают навстречу журналистскому будущему или становятся отличными фотографами и иллюстраторами. |
| Ключевые слова воспитательной практики | внеурочная деятельность; дополнительное образование; школьная газета; творческое саморазвитие личности; формирование учебно-познавательных компетенций; самореализация старшеклассников в поликультурной среде; социальная активность выпускников школы. |
| Актуальность внедрения воспитательной практики | Произведения Туфана Миннуллина, великого драматурга и писателя татарского народа, имеют большое воспитательное значение для учащихся.<br>Творчество Туфана Абдулловича отличается тематическим разнообразием. Он писал в самых разных жанрах – от водевиля до трагедии и философской притчи. Умел говорить об острых социальных и национальных проблемах в легком жанре комедии. Его называли королем комедии в современной татарской литературе. Он был самым успешным из татарских драматургов. Автор более полусотни пьес, вошедших в золотой фонд татарской драматургии. В республике нет ни одного театра, где бы не ставились его произведения. В этом ряду особое место занимает Камаловский театр, с которым драматург сотрудничал много лет. В разное время на сцене Камаловского театра шли (некоторые идут до сих пор) его пьесы «Четыре жениха для Диляфруз», «Ильгизар + Вера», «Баскетболист» и другие. Пьесы драматурга наполнены оптимизмом и стремлением жить достойно. Особенно ярко это проявилось в образе Альмандара.<br>Он сам был лидером литераторов всего татарского мира не по формальному признаку. Все наши писатели признавали его безусловным аксакалом |

| | |
|---|---|
| | татарской литературы, более того, он был честью и совестью всего народа. Его книги, пьесы, поступки были исключительно правдивы, точны, поучительны.<br>В результате посвящения этого номера газеты творчеству Туфана Миннуллина учащиеся ближе познакомились с его творчеством и призведениями, поняли, что он очень интересная личность.<br>Проект предоставляет возможности для раскрытия творческих способностей в различных сферах:<br>написание и редактирование текстов, создание иллюстраций, освоение публицистических жанров (статья, интервью, блиц-опрос, анкетирование).<br>В процессе работы над номером планируется сбор информации о творчестве Туфана Миңнуллина, слова великих людей о нем, стихи, посвященные ему, фотографий из постановки «Гөргөри кияүләре» в исполнении учеников 11 класса, написание статьи о постановке «Гөргөри кияүләре» и о приезде великого драматурга в нашу гимназию. |
| Цель и задачи воспитательной практики | Цель проекта: подготовка специального выпуска школьной газеты ««Гимназия сулышы» посвященной светлой памяти великого драматурга и писателя Туфана Миннуллина<br>Задачи проекта:<br>1. Собрать сведения о жизни и творчестве автора<br>2. Подготовить иллюстрированный материал.<br>3. Отобрать тексты для публикации.<br>4. Оформить газету. |
| Целевая аудитория воспитательной практики | группа обучающихся 8-10 классов; помощники – учащиеся гимназии, кураторы-учителя. |
| Краткий анализ воспитательной практики | Представлен в приложении № 1 к Паспорту воспитательной практики |
| Технологии и методы реализации воспитательной | Технологии:<br>- воспитательная технология; |

| | |
|---|---|
| практики | - педагогическая;<br>- технология проектного обучения.<br>- гуманно – личностная<br>- коллективных творческих дел<br>- технология «Создание ситуации успеха»<br>-критического мышления<br>-интерактивный<br>-проблемный<br>-поисковый<br>Методы: личностно – ориентированный подход учитывает особенности учащихся, способствует обучению свободно и творчески мыслить;<br>коммуникативная направленность даёт учащимся возможность общаться в процессе создания, выпуска и реализации газеты;<br>деятельный характер обучения позволяет работать<br>индивидуально, в парах, группах;<br>взаимосвязанное обучение написанию заметок и статей, подготовке постоянных рубрик, разделов, тематических выпусков газет;<br>поэтапность обучения от простого к сложному<br>Формы работы по программе: экскурсии, классные часы, беседы, обсуждения, консультации, презентации, занятия; конкурсы, викторины, игры,<br>праздники, мероприятия, представления, выступления, фестивали; НПК, дебаты, дискуссии, круглые столы, конференции; встречи с выпускниками, интересными людьми и т.д.<br>способствует свободному владению письменной речью при создании текста. |
| Ресурсы, необходимые для реализации воспитательной практики | Ресурсы, позволяющие реализовать воспитательную практику:<br>- педагогические кадры;<br>- привлечение родителей;<br>- активация внутренних ресурсов школы;<br>- сетевое взаимодействие. |

| | |
|---|---|
| Период реализациивоспитательной практики | Период: долгосрочный<br>В приложении № 2 к Паспорту воспитательной практики представлен план-график реализации воспитательной практики по Диаграмме Ганта |
| Ожидаемые результаты воспитательной практики | Повышение социальной активности учащихся.<br>Развитие ценностной ориентации и творческой активности учащихся.<br>Развитие эстетических вкусов учащихся.<br>Чёткая периодичность выхода газеты.<br>Появление у газеты новых авторов.<br>Повышение интереса читателей к газете. |

**Описание воспитательной практики**

Туфан Миннуллин... "Каждое его произведение-это поэзия. Он-смелый литератор, способный высказывать мудрые суждения даже в опасный период цензурного произвола. Внес значительный вклад в развитие театра. На протяжении многих десятилетий он и плакал, и размышлял, и утешал, и будил наш народ.- пишет Марсель Галеев. Да, действительно, правдивые слова. Татарскую сценическую литературу последних 60-х годов XX века и сегодня невозможно представить без творчества писателя-драматурга Туфана Миннуллина. Вот уже 50 лет он ведет в Татарском искусстве полемику о добре и зле, о любви и ненависти, о величии и низости, о жизни и смерти.

“Выдающийся драматург, государственный и общественный деятель Туфан Габдуллович Миннуллин – одна из тех сильных личностей, которые своими действиями заслуживают народной памяти. Наш старейшина, великий наставник Туфан ага, который, несмотря на то, как дуют современные ветры, воспринимает горести и радости родного народа как свои, воспевает их… Имя великого писателя, его мудрое слово сопровождают нас и сегодня. Надеюсь, так будет всегда».(Рустам Миннеханов)

**В газете использованы следующие рубрики:**

**“Новости гимназии”**

Ученики нашей гимназии с любовью читают его произведения, с интересом смотрят спектакли. Это рубрика рассказывает о том, что в честь 85-летия со дня рождения Туфана Миннуллина в нашей гимназии прошли различные мероприятия. Ученики 11-х классов поставили пьесу драматурга “Гөргөри кияүләре ”. Каждый ученик блестяще, мастерски исполнил свою роль. Светлые впечатления от этого спектакля надолго останутся в сердцах учащихся нашей гимназии. Выставка книг «Туфан Миннуллин – яркое солнце татарской литературы» вызвала большой интерес у читателей. Его

произведения бессмертны. Своими произведениями он призывает нас к светлому пути, учит жить добром, познавать вкусы мира.

В рубрике **“Туфан- киңкырлы әдип”** мы стремились познакомить с деятельностью драматурга. Учащийся 6го класса Сабитов Айнур собрал информацию о том, что Т.Миннуллин еще и человек, попробовавший свое творчество во всех сферах, артист драматического театра имени Минзаля, артист Татарского государственного академического театра имени Г. Камаля, лауреат премий Мусы Джалиля и Тукая, заслуженный деятель Россия, депутат Госсовета Татарстана. Т. Миннуллин – один из татарских драматургов, пьесы которого больше всего ставятся на сценах нашей страны. Его сценические произведения ставились на сценах русских драматических театров Татарстана, Башкортостана, Узбекистана, Марийского, Калмыцкого, Мурманска, Новокузнецка, Астрахани, Горького, Мичурина и других городов.

В рубрике **“Туфан сүзе сагындыра”** написали мудрые слова, сказанные автором, взяты из книги Туфана Миннуллина «Насыйбулла боткасы».

В рубрике **“Туфан ага турында истәлекләр”** мы написали воспоминания, связанные с Туфаном Миннуллиным. Прочитав эти воспоминания, у вас возникнет ощущение, будто вы разговариваете с Туфаном, картина, связанная с воспоминанием, обновляется

2012 году в дни Мусы Джалиля на встречу с учащимися приехал Туфан Миңнуллин. Об Этом событии мы написали в рубрике **“Хатирәләрне яңартып”**

Рубрика **“Укучылар сүзе”** - вы можете познакомиться с рассуждениями учеников, где каждый написал свои мнения и взгляды о творчестве драматурга.

Выбранная тема работы не только актуальна, но и интересна и имеет практическую значимость. Работая над раскрытием вопросов, поставленных в ходе изучения темы, я сделал вывод о том, что великие личности, такие как Туфан Миннуллин, живут в наших сердцах, память остается жива, по сей день. Данная работа имеет продолжение, т.е. мы будем продолжать работать над изучением жизни и творчества Т.Миннуллина, прочитаем еще много познавательных, воспитательных произведений автора.

При сборе материала, записи воспоминаний нам еще раз хотелось встретиться с автором, послушать его мудрые слова...

Молодое поколение должно поимённо знать таких людей.

Приложение № 1
к Паспорту воспитательной практики

**Краткий анализ воспитательной практики**
**Школьная газета – «Гимназия сулышы»**

| **Внутренние факторы** | **Внешние факторы** |
|---|---|
| *Сильные стороны* | *Возможности* |
| 1.Введение разнообразных инновационных педагогических технологий, форм и методов воспитания для развития нравственных качеств личности через проектную деятельность.<br>2. Привлечение родителей к участию в общешкольных мероприятиях.<br>3. Социальное партнерство с организациями и учреждениями села, муниципального района, обеспечивающее развитие нравственных качеств личности через проектную деятельность.<br>4. Привлечение увлеченных детей, учителей, родителей к сбору информации в школьную газету. | 1.Вовлечённость всего педагогического коллектива в деятельность школьной газеты. 2.Проявление активности, инициативы, творчества в организации и проведении мероприятий при сборе информации. 3.Овладение разнообразными формами и методами поиска знаний, практическими умениями, в том числе исследовательскими.<br>4.Обогащение знаниями о проблемах, связанных со школьными и способах их решения.<br>5.Проявление исторической культуры, выражающейся в переводе знаний в норму поступка.<br>6. Введение разнообразных инновационных педагогических технологий, форм и методов работы.<br>7. Повышение статуса школы в воспитательном пространстве района |
| *Слабые стороны* | *Риски* |
| 1.Дополнительная нагрузка классного руководителя, учителя истории и обществознания, но одновременно это и сильная сторона – руководитель школьной газеты должен любить эту работу.<br>2. Недостаточно средств, выделяемых для школ, для их оборудования. | 1. Дополнительная нагрузка учащихся. |

Приложение № 2
к Паспорту воспитательной практики

# План-график реализации воспитательной практики
# Школьная газета – «Гимназия сулышы»

| № | Наименование этапа | Длительность | Временные рамки проекта (может указываться в днях, месяцах) | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Период 1 | Период 2 | Период 3 | Период 4 | Период 5 | Период 6 | Период 7 |
| 1. | Согласование плана воспитательной работы школьной газеты на 2023-2024 учебный год | 3 дня | 29.08 - 31.09 2022 | | | | | | |
| 2. | Изучение биографии и творчества Туфана Миннуллина | месяц | 01.09-05.10 2022 | | | | | | |
| 3. | Чтение книг автора | месяц | | 10.10-09.11 2022 | | | | | |
| 4 | Обсуждение произведений автора | В течение уч.года | | | 15.09. 2022-25.05. 2023 | | | | |
| 5 | Просмотр спектаклей Т.Миннуллина | В течение уч.года | | | | 15.09 2023 – 27.05. 2023 | | | |
| 6 | Рисунки по прозведениям Туфана Миннуллина | месяц | | | | | 11.01-12.02. 2023 | | |
| 7 | Просмотр спектакля Т.Миннуллина «Гөргөри кияүләре" в исполнении учащимися 11класса | месяц | | | | | 13.02-10.03. 2023 | | |
| 8 | «Проба пера» Написание | месяц | | | | | 13.03-10.04. | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | сочинений – рассуждений про творчеству Т.Миннуллина | | | | | | 2023 | | |
| 9 | «Проба пера» Написание статьи про спектакль «Гөргөри кияүләре” при постановке учащимися 11 класса | месяц | | | | | | 10.04-10.05. 2023 | |
| 10 | Подготовка текстового материала. | 5 дней | | | | | | 11.05-15.05. 2023 | |
| 11 | Выпуск газеты | 2 дня | | | | | | | 15.05-16.05 2023 |
| 12 | Подведение итогов работы по выполнению воспитательной практики | 1-2 дня | | | | | | | 17.05. 2023 |
| 13 | Составление плана работы на следующий учебный год | 1-2 дня | | | | | | | 18.05-19.05. 2023 |

Приложение № 3
к Паспорту воспитательной практики

**ДӘВЕРЛӘРНЕ АЧАР АЧКЫЧЫМ БАР – РӘХМӘТ ЯУСЫН ТУГАН ТЕЛЕМӘ!**

# ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

**“Бакый Зиятдинов исемендәге Карадуган гимназиясе”**
**май, 2023 нче ел, 5 нче сан**



**Газетабызның тәүге саны**
**Төкле аягың белән!**
**Мәктәбебез тормышына**
**Өстәп тор син ямь!**

***Газетабызның әлеге саны язучы, бөек драматург Туфан ага Миңнуллинның якты истәлегенә багышлана.***



*Әлеге санда*:

*Гимназиябез яңалыклары*
*Туфан-киңкырлы әдип*
*Туфан сузе сагындыра*
*Укучылар сузе*
*Туфан ага турында истәлекләр*
*Хатирәләрне яңартып...*
*Туфанлы мизгелләр*
*Елмаеп, көлеп алыйк!*

***«Күренекле драматург, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Туфан Габдулла улы Миңнуллин – эш-гамәлләре белән халык хәтерендә истә калырга лаек булган көчле шәхесләрнең берсе. Замана җилләре ничек исүгә карамастан, туган халкының кайгы-хәсрәтен, шатлык-куанычларын үзенеке дип кабул итүче, шуны җырлаучы Туфан ага безнең аксакалыбыз, олуг остазыбыз иде…***

***…Олуг язучының исеме, аның зирәк сүзе безне бүген дә озатып бара. Бу һәрвакыт шулай булыр, дип ышанам».***


***Рөстәм Миңнеханов***

***«Мин иң элек аны халкыбызның иң булган, иң лаеклы улларының берсе, дип саныйм. Уйлавымча, аны Ходай бу дөньяга татар халкының яклаучысы, аның телен, моңын, җанын саклаучы итеп яраткан. Халык күңеленең гел чыңлап торган сизгер бер кылы, дип әйтер идем хәтта. Аңа Туфан исеме дә очраклы бирелмәгән, дигән фикер белән килешәм. Зур шәхес. Көчле шәхес».***

***Минтимер Шәймиев:***

# Гимназиябез яңалыклары

*“Аның һәрбер әсәре – үзе бер шигърият. Ул – цензура балтасының хәтәр чорында да хикмәтле фикерләр әйтә алган кыю әдип. Театрны үстерүгә Туфан галәми өлеш кертте. Ничә дистә еллар буена ул халкыбызны елатты да, уйлатты да, юатты да, уятты да.”- дип яза Марсель Галиев. Әйе, дөрестән дә, хак сүзләр. XX гасырның 60 нчы елларыннан соңгы һәм бүгенге татар сәхнә әдәбиятын язучы-драматург Туфан Миңнуллин иҗатыннан башка күз алдына да китереп булмый. Менә 50 ел инде ул татар сәнгатендә яхшылык һәм явызлык, мәхәббәт һәм нәфрәт, бөеклек һәм түбәнлек, яшәү һәм үлем турында бәхәс алып бара. Аның пьесаларын, хикәяләрен, публицистик әсәрләрен, гомумән алганда, иҗатын халкыбыз бик ярата.*



*Гимназиябез укучылары да аның әсәрләрен яратып укыйлар, спектакльләрен кызыксынып карыйлар. Туфан ага Миңнуллинның тууына 85 ел[illegible] иҗатын зурлап, хөрмәт[illegible]ле чаралар узды.*

*[illegible] укучылары [illegible] кияүләре”н [illegible] үз ролен бик [illegible] карды. Әлеге [illegible] якты матур [illegible]без укучылары кү[illegible] сакланыр әле.*

*“Туфан Миңнуллин – татар әдәбиятының якты кояшы” дип исемләнгән китаплар күргәзмәсен укучылар бик кызыксынып карады. Туфан ага үзе, әсәрләре – үлемсез. Ул безне әсәрләре аша якты юлга өнди, яхшылыкка, дөньяның тәмен белеп яшәргә өйрәтә.*





*Яңалыкларны 9нчы сыйныф укучысы- Гал*

# Туфан – киңкырлы әдип

***Газетабызның әлеге битендә драматургның эшчәнлеге белән таныштыруны максат итеп куйдык. Күпләр аны драма язучы итеп кенә белә. Ә чынлыкта исә, ул- иҗатын бар өлкәдә дә сынап караган әдип, Минзәлә драма театры, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында артист, Муса Җәлил һәм Тукай премиясе лауреаты, Россиянең атказанган эшлеклесе, Татарстанның дәүләт советы депутаты.***

**Пьесалары:**


**Диләфрүзгә дүрт кияү» , «Ир - егетләр», «Канкай угылы Бәхтияр», «Әлдермештән Әлмәндәр», «Дуслар җыелган җирдә», «Адәм баласына ял кирәк», «Моңлы бер җыр», «Монда тудык, монда үстек», «Әниләр һәм бәбиләр» «Ай булмаса, йолдыз бар», «Яшьлегем — җүләрлегем», «Бәйләнчек», «Үзебез сайлаган язмыш», «Уйланыр чак», «Китәр юлың еракмы?», «Ак тәүбә, кара тәүбә», «Кырларым-тугайларым», «Хушыгыз», «Миләүшәнең туган көне» һ.б.**

**Туфан Миңнуллинга бирелгән премияләр:**

**1974 елда «Нигез ташлары» комедиясе һәм «Үзебез сайлаган язмыш» драматик хикәясе өчен Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге Дәүләт премиясе;**
**1979 елда «Ай булмаса, йолдыз бар» әсәре буенча Әлмәт драма театрында куелган спектакль өчен Татарстан АССРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе;**
**1979 елда Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелган «Әлдермештән Әлмәндәр» спектакле өчен РСФСРның К. Станиславский исемендәге Дәүләт премиясе;**
**Татар театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен аңа Татарстан АССРның (1978) һәм РСФСРның (1984) атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем;**






**Т.Миңнуллин — пьесалары илебез сәхнәләрендә иң күп уйнала торган татар драматургларыннан берсе. Аның сәхнә әсәрләре Татарстан, Башкортстан, Үзбәкстан, Мари Иле, Калмык, Мурманск, Новокузнецк, Әстерхан, Горький, Мичурин һәм башка шәһәрләрнең рус драма театрлары сәхнәләрендә куелды.**


## Хезмәтләре:













**Мәгълүматларны 6нчы сыйныф укучысы-Сабитов Айнур туплады**

# Туфан сүзе сагындыра...

***Туфан абыйны бик күпләр сагына… Аның үзен, аның туры, акыллы сүзен...***

*Туфан абый сүзенә мөрәҗәгать итмәгән кеше дә юктыр. Кулымда аның 2010 елда чыккан «Насыйбулла боткасы» китабы. Укыган саен укыйсы килеп тора бу китапны. «Телефоннан сөйләшүләр» дип аталган кызыклы язмалары да шушы китапка кертелгән. Үзенең телефоннан корган кайбер әңгәмәләрен сүзен сүзгә теркәп куйган ул. Сезгә кайберләрен тәкъдим итәбез.*

***Үзебезнең көй***

***Искерә төшкән яшел кәрәзле телефонын оныгы Данияр кәттәрәк телефонга алыштырып, ул телефонга әллә нинди функцияләр тутырып биргәч, Туфан абый берничә көн шуның белән йөрде. Бик ярата иде ул техника алырга, аны өйрәнеп мәш килергә. Ләкин техника гына Туфан абый кулына каләме кебек виртуозларча буйсынмый иде.***

***Аның яшел телефонына Нәҗибә апа шалтыратканда: «Җир җиләгем, кура җиләгем, Сагынып көтәм сине, чибәрем» җыры яңгырый иде. Ул җырны Туфан абый озак кына тыңлый әле, шалтыратуга ук ашык-пошык җавап бирми. Яшерен-батырын түгел, кем шалтыратканын шундук аңлаганлыктан, мин (башка кызлар да шулай булгандыр әле, шулайдыр) әлеге сөйләшүләрнең үземә ишетелгән өлешен интонациясен, «тонның җылылык микъдары»н бәяли-бәяли тыңлый идем. Бернинди төче сүз әйтми генә шундый матур сөйләшә иде Туфан абый Нәҗибә апа белән.***

***Ә бу яңа дигән телефонда әллә нинди генә заграничный галәмәт көй уйный иде. Бу хәлдән Туфан абый гына түгел, без дә бераз дискомфорт кичердек, теге матур көйне ишетеп ияләшкән идек. Бер атналап яңа телефон белән йөргәч, беркөнне кабат иске яшел телефоны белән килде Туфан абый. Күрми дә калыр идек, берзаман телефонда теге җыр җырлап җибәрмәсенме! И куанышты шуңа. «Тегесенә Нәҗибә шалтыратканда бу матур көйне җайлап булмады, әйе… Шуңа яңадан монысын алдым», – диде Туфан абый.***




**Безнең гомер – мең томлык тарих китабы битендә черки эзе**

**Мескенләнмә, югыйсә шәхес була алмыйсың**

**Дошманыңны елатасың килсә, көлеп яшә**

**Эшләгәндә киемең кеше көләрлек булсын, бәйрәмдә кеше көнләрлек булсын.**

**Акыллы буласың килсә, акыллы кешеләр белән генә сөйләш**

**Ачуың кайнаганда пешәсең килмәсә, дәшми түз**

**Дошманыңны хөрмәт ит, синең чын бәяңне ул гына белә**

**Егылудан курыксаң, шуыш, шуышканнар егылмый**

**Кәҗә койрыгы кебек кыска гомерне сыер шикелле күшәп уздырма**

**Акылыңны сыныйсың килсә, ахмак кеше белән**

**Авызына микрофон тыксаң, балык та җырлый хәзер**

**Кешенең кеше булуы ояла белүендә**

**Вәт замана: әнисе урысча белми, баласы татарча белми**

**Яшисең килсә, үләргә өйрән**

**Мәгълүматларны туплаучы: 8нче сыйныф укучысы -Хөсәенова Айзилә**

# …ага турында истәлекләр



***Газетабызга материаллар туплаган, Туфан Миңнуллинның хезмәтләрен барлаган вакытта аңа бәйле истәлекләрне теркәдек. Күп алар. Әлеге истәлекләрне укыгач, Туфан абый белән сөйләшкән кебек буласың, хатирәгә бәйле картина яңара.***

***Туфан Миңнуллин депутатлар арасында иң өлкән яшьтә булу сәбәпле, берничә чакырылышның беренче утырышларын татар телендә ачып җибәргән. Депутат буларак ул һәрвакыт татар теле, мәдәнияте, милләте язмышы турында чыгышлар ясаган, татар халкын дәүләт дәрәҗәсендә яклый торган булган.***

“Туфан беркайчан да битараф калмый иде. Берсендә, рәтләр арасыннан трибунага атлаганда үз-үзенә сөйләнгәнен ишеттем. “Беләм инде үткәрмәягегезне, әмма барыбер әйтмичә кала алмыйм, намусым кушмый”, – дип кабатлый-кабатлый трибунага менде. Ул намусына тугры булып яшәргә тырышты. Туфан Миңнуллин язучы, драматург кына түгел, ул – сәясәтче дә иде”- дип яза **Фәндәс Сафиуллин**

“ Без Туфан ага белән 45 ел аралашып яшәдек. Ул табышмак иде, аның Пәйгамбәрләрчә алдан күрә белү сәләте бар иде. Депутатлык эшендә дә иң кирәкле сүзне иң кирәкле вакытында әйтә белә иде. Ул кешеләр белән аралашырга яратты. Үзе дә акыллы кешеләр белән аралашырга, тәкъдимнәрен ишетергә, фикерләшергә кирәк дип әйтә иде. Бу белемнәрне ул дәүләт эшендә һәм иҗатында да файдалана иде.

Аның 70 яшьлек юбилее уңаеннан бер мәктәптә узган чарага барган идек. Укытучы шунда: “Туфан Миңнуллинның асыл сыйфаты һәм популярлыгы шунда – ул гади халык арасыннан чыккан кеше”, – диде. Мин шаяртып: “Юк, ул гади халык арасыннан чыккан кеше түгел”, – дип бүлдердем. Туфан ага гаҗәпләнеп миңа карады. “Ул – бүген дә гади халык арасында”, – дип аңлаттым мин.

Туфан Миңнуллин ярдәм иткән кешеләр, аның тырышлыгы белән төзелгән һәм төзекләндерелгән мәктәпләр, китапханәләр, клубларның исәбе юк. Без аны әле елдан-ел ныграк сагыначакбыз. Ул иҗат иткән әсәрләрнең популярлыгы да артачак кына. Кеше янәшәдә булганда аның бөеклеген күреп җиткермибез, әмма еллар узган саен моны аңлый барасың. Бүген безгә бигрәк тә парламентта Туфан ага җитми.”
ТР Дәүләт Советының Мәгариф, фән, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Татарстанның халык шагыйре: **Разил Вәлиев**

“Без Туфан абый белән бик күптәннән аралаша идек. Тукай премиясе комиссиясе утырышларында бәхәс чыкканда мин гел аның яклы була идем, – дип сөйләде Зилә Сөнгатуллина. – Әле яшьрәк чакта, ул депутат булганчы бер очрак истә калды. Яңа ел бәйрәмнәре иде. Очраклы рәвештә троллейбуста күрдем. Мин Туфан абыйны бәйрәм белән котлап, Яңа ел яңа бәхетләр китерсен, дип теләкләремне җиткердем. Ә ул җавапка: “Бәхетнең искесе дә яхшы аның”, - дип елмаеп җавап кайтарды. Тапкыр кеше, җор телле иде.” **Татарстанның һәм Россиянең халык артисты- Зилә Сөнгатуллина**

**Илдар ЮЗЕЕВ**
**КОТЛАУ**

Халкыбызның яшәү дәртен
Син расларга туган күк,

**Мөдәррис ӘГЪЛӘМ**
**БӘҺАСЕЗ ЗАТ**

Әйтәләр бит: кояшта да
Гыйбрәтле таплар була.
Халыкта да мәңге калыр
Бәһасез затлар була.

**Роберт МИҢНУЛЛИН**
**ТУФАНГА КИЛЕШӘ УЛ!..**

Бу нәрсә бу? Туфан таша,
Татарны Туфан баса:
Театр гына ярар иде,
Парламент туфанлаша.

Әдәбиятыбызның көче –
Хәтта ике Туфанлык!
Үзең иҗат иткән Тукай
Тәбрикләп кочар иде,
«Моңлы бер җыр»ыңнан Муса
Кулыңны кысар иде.
Театрыбызның атасы
Г.Камал бүген сөеп,
Сиңа сокланып карый күк:
«Афәрин, балам!» – диеп.
Туфаның – бөек адашың
Котларга кайтыр кебек,
«Минем исемне акладың,
Рәхмәт!» – дип әйтер кебек.
Бер Тукайлы, бер Такташлы
Һәм дә ике Туфанлы
Бик бәхетле әдәбият
Котлый бүген Туфанны!
Театрның гына түгел,
Син – халыкның баласы,
Барыр юлларың бик ерак –
Яңа үрләр аласы!
Күз тимәсен, рухы көчле,
Җәлилләрчә – Туфан нык,
Син сәнгатьнең яшәү көчен
Раслау өчен туган күк,
Гомер юрый сиңа халкың,
Ике, өч, дүрт Туфанлык!

**Мәгъсум ХУҖИН**
**ИХЛАСЛЫК**
Туфан Миңнуллинның ихласлыгы башка яхшы якларыннан – эшчәнлектән, дуслыкта тугрылыктан, тәвәккәллектән һәм башкалардан – калкурак булып күренә миңа. Әйе, язганында да, бүтән гамәлендә дә ихлас ул. Укучылар һәм тамашачылар аның әсәрләрен тормышны эчкерсез чагылдырулары өчен ихластан кабул итә. Язган һәр сүзендә риясыз Туфан.
*1995*

**Истәлекләрне 7нче сыйныф укучысы-**
**Калимуллина Зилия туплады**




# Хатирәләрне яңартып...

***2012нче елда  Муса Җәлил көннәренә Туфан ага Миңнуллин гимназиябезгә  очрашуга килде. Газетабызда хатирәләрне яңартып, әлеге очрашу турында мәкалә урнаштыруны уңай дип таптык.***

Туфан Миңнуллинның Муса Җәлил музеена беренче тапкыр гына килүе түгел, шулай да ул рәхәтләнеп риза булды. Аның әсәрләрен яратып, кызыксынып укыган мәктәп балалары да аны бик җылы каршы алдылар, яраттылар.  Гимназиябездә ел саен М.Җәлил премиясе лауреатлары белән очрашулар үткәрелә.  Әлбәттә, аны чакыру юкка гына түгел, чөнки Т. Миңнуллин - «Нигез ташлары» комедиясе һәм «Үзебез сайлаган язмыш» драматик хикәясе өчен 1974 елда Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булган һәм 1981нче елда Муса Җәлилгә багышлап “Моңлы бер җыр” публицистик драмасын иҗат иткән драматург.

Очрашу барышында укучылар М.Җәлил шигырьләрен яттан сөйләп, җырлар җырладылар, әсәрләреннән өзекләр күрсәттеләр, драматургка төрле сораулар биреп, кызыклы гына җаваплар да алдылар. Т. Миңнуллин М.Җәлил иҗатына карата үзенең фикерләрен җиткерде, җирдә каһарманнарның күп булуын, ә Муса Җәлилгә тиңнәр юклыгын әйтеп үткәннән соң, сүзен болай дип дәвам итте: “*Җәлилебез исемен ялгышып кына булса да түбән төшерергә маташу гөнаһтыр. Ә инде Җәлилдән махсус рәвештә кер эзләүне җинаятькә тиң дип саныйм. Андыйлар да бар. Күрәсең, Җәлил һәм аның көрәштәшләренең булуы кемнәргәдер ошамый. Татар халкы хәтерендә аларның герой булып саклануы кемнәрнеңдер эчен пошыра. Җәлилнең томкынлыктагы антифашистик көрәшенең бөтенесен сызып ташлаган очракта да ике нәрсәне без һичшиксез инкяр итә алмыйбыз. Беренчесе – Германиянең Империя суды, җитди дәлилләр тапмыйча, ул теләсә кемне үлем җәзасына хөкем итми. Икенчедән, үлем җәзасын көтеп торганда үлемсез шигырьләр язу өчен гаҗәеп зур рухи көч һәм талант кирәк. Бу геройлык түгелмени? Кыскасы, Җәлилебездән кер эзләп казыну әдәпсезлек һәм әхлаксызлык. Кирәкмәгән җирдә күп казынсаң, үзең төшеп чыга алмаслык чокыр казуың бик ихтимал.”*



Очрашуда укучылар Т. Миңнуллинның “Моңлы бер җыр” публицистик драмасының бер өлешен сәхнәләштерделәр. Драматургның һәм актерларның таланты ярдәмендә каһарман шагыйребез образы татар театры сәхнәсендә үзенә лаеклы урынны алды. Без Җәлилне бөек шагыйрь буларак кына түгел, яхшы киңәшче, чын дус була алган гап-гади ир-егет итеп тә күз алдына китерә алдык.Укучыларның “Ни өчен әсәрнең исемен "Моңлы бер җыр" дип атадыгыз?” дигән сорауга Туфан ага болай дип җавап бирде: “*Чөнки Җәлил һәм аның көрәштәшләренең гомере бер моңлы җырга ошаган. Җыр озак дәвам итми, ул кыска.Ә моңлы итеп тирән сагышы, кайгы-хәсрәте булган кеше генә җырлый ала. Мин җәлилчеләрнең тормышы кыска һәм сагышлар белән тулы булачагына ишарәләдем, кеше психологиясенә тагын да тирәнрәк үтеп керү, замандаш образларын эзерәк гомумиләштерү, проблемаларны сәнгатьчә үтемлерәк хәл итү мөмкинлекләрен эзләдем”*.

Әсәрнең русчага тәрҗемә ителгән варианты барлыгын һәм аның "У совести вариантов нет" (М. Җәлил Шәфи Алмасның "гомерегезне саклап кала ала идегез" дигән сүзенә: "Намус, Вөҗдан бер генә, вариантлар

юк,"- дип җавап бирә.) дип аталуын белү укучыларда кызыксыну уятты.

Бу әсәр нигезендә куелган спектакльдә яшәү белән үлем фәлсәфәсе, аның азатлык көрәшендәге, гомумән, кеше язмышындагы роле үзенчәлекле һәм тирән ачылды.

Туфан ага Миңнуллин белән очрашу музейда дәвам итте. Ул анда укучыларны “Кызыл ромашка” штабына кабул итүен карады, укучыларның шигырьләр сөйләвен тыңлады, М.Җәлил турындагы истәлекләрне яңартты. Музеебыз, гимназ... мин сезгә та... барган ... ага



2012нче елның 2нче маенда дөньядан китеп барды.

**Мәкалә авторы: татар теле һәм әдәбияты укытучысы –Гарифуллина Эльмира Мәсхүт кызы**










## Укучылар сү

*Гимназиябез укучылары Туфан Миңнуллин иҗатына гашыйк. Әсәрләрен яратып укыйлар, спектакльләрен кызыксынып карыйлар. Драматургның иҗатына карата үз фикерләре, карашлары бар...*

Минем иң яраткан язучым- Туфан Миңнуллин. Драмаларын кызыксынып укыйм. Спектакльләрен бик яратып карыйм. “Әлдермештән Әлмәндәр” спектаклендәге Әлмәндәр картка хөрмәтем бик зур.Тормышка, яшәүгә мәхәббәте чиксез булганга мөкиббәндер без аңа. Әҗәл тиклем Әҗәл белән тарткалашырга кыюлыгы җиткән, туксанын тутырган картка ничек сокланмыйсың, я? Хәер, әҗәле дә башта гына куркыныч тоела, күз күнегә торгач, тәмам үз булып бетә ич. Аннан килеп, ник әҗәлдән куркып торырга әле, иртәме соңмы барыбер киләчәк, һәммәбезне күтәреп алып китәчәк бит ул. Туу булган җирдә әҗәл дә булмый калмый. Дөресен әйтим, спектакльләргә мөкиббән кеше түгелмен, әмма “Әлдермештән Әлмәндәр” спектакле мине әсир итте. Бу спектакльнең тарту көче шаккаткыч, һаман карыйсы килә.
**Исхакова Нәфисә – 8нче сыйныф укучысы**



Бүгенге көндә күп кеше Туфан аганың язмаларын яратып укыйлар,аның сәхнә әсәрләрен һәрдаим карап баралар. Мин үзем, гомумән, аның иҗатына гашыйк кеше. Ул чын безнеңчә гади телдә яза, бүгенге көндәге иң кайнар проблемаларны
**Лотфуллина Исламия - 8нче сыйныф укучысы**

Туфан Миңнуллин әсәрләрендә үз халкының бөтен даирәләрен дә кочагына алып сурәтли,милләтнең барлык катлам кешеләрен дә чагылдыра. Иҗатын ул халык язмышы белән тыгыз бәйли, нинди булса бер мөһим мәсьәлә күтәрелмәгән әсәре юк аның. Халкы белән шатлана,халкы белән бергә кайгыра. Йөрәген әрнеткән нәрсәләр турында курыкмыйча әйтә һәм житешсезлекләрнең бетүен таләп итә.Әйе,әйе,сәхнә аша таләп итә ул үз халкының камилләшүен.
**Галиәхмәтова Регина - 9нчы сыйныф укучысы**

Туфан Миңнуллинның “Әлдермештән Әлмәндәр” әсәрен кызыксынып укып чыктым. Искиткеч әсәр! Күп кешегә Әлмәндәр карттан үрнәк алырга кирәк, минемчә. Дөньяны яратучы, шаян, җор телле бу геройга сокланмый мөмкин түгел!
**Зиятдинова Гөлсем -8нче сыйныф укучысы**

Т.Миңнуллин иҗатында халкыбызның милли өметләре, хисләре, бай образлар дөньясы искиткеч тирән һәм тулы чагылды. Чынбарлыкны сурәтләүдә һәрвакыт тарихи дөреслеккә омтылган иманлы милли әдип ул Т.Миңнуллин. Ил язмышы, халык язмышы хакында сүз барганда ул беркайчан да читтә калмый, киресенчә, алдын-артын карамыйча, ярсый-ярсый ут эченә ташлана. “Туктагыз әле, агайне, алай түгел, болай бит ул”, - дип күпләрнең фикерен үз ягына борып җибәрә ала.
**Нуриева Марьям - 8нче сыйныф укучысы**



*Әдәбият – сәнгать тирәсендә йөрүчеләрнең генә түгел, күп кешенең күңелендә шигырь ята. Шигырь!... Иң авыр вакытларымда шигырь язам мин. Кайвакыт аларның кайберләрен, кыланып, бастырып та чыгарам. Кыланып. Шигырьгә охшап бетмәгәннәрен. Мин – бары тик*

*драматург кына. Шул вакытта шигырь язып карамаган язучыны да язучыга санамыйм,- ди Туфан ага үзенең "Сайланма әсәрләр"ендәге бер әңгәмәсендә. "Кыланып" кына язылсалар да, мәгънәле шигырьләр... Сез дә укып карагыз әле...*

Төшемдә мин таш гасырга
кайтып килдем,
Кыргыйларга шигырьләрем
укып йөрдем.
Шигыреңне ташка уеп яз, диделәр.
Шагыйрьлекнең ни икәнен
шунда белдем

Акчаң күпме? Юк-юк, әйтмә,
белеп торам.
Күп икәнен белгән килеш
көлеп торам.
Телисеңме, кешеләргә әйтер өчен
Син фәкыйрьгә бер җылы сүз
биреп торам.

Туп типкәндә, аяк белән
уйнау яхшы,
«Гол! Гол!» диеп сызгыру һәм
чинау яхшы.
Ни кызганыч, аяк белән
уйлап булмый,
Ни әйтсәң дә, башың белән
уйлау яхшы.

Мичкә – пүлән, самавырга
шакмак кирәк,
Бии-бии җырлар өчен такмак кирәк.
Албастылар, җен-пәриләр

Бу дөньяда кимлегеңне
белдертәләр,
Елаталар, кирәк икән көлдертәләр.
Әнә, кара: атка камыт кидергәндә,
Аның башын ничек итеп идертәләр.

Ап-ак карлар явып үткән үзәннәргә,
Ак төс иңгән без табынган
гүзәлләргә…
Сокланып һәм моңсуланып
карап торам
Бабай диеп үзәгемне өзгәннәргә.

Мәхәббәт ул нәрсә димсең?
Хикмәттер ул –
Бал ягылган ике телем икмәктер
ул:
Бер мизгелдә балын
ялап бетергәчтен,
Ипи кимереп
икәү гомер итмәктер ул.

Йә, нишлибез? Син – түрә,
мин түрә түгел,
Мин – бер гидай,
син үзеңә күрә түгел.
Мин шул инде – җыен юк-бар
сөйләп йөрим,
Ләкин синең дә сүзләрең сүрә түгел.

Шигырьләрне 5нче сыйныф укучысы – Нургалиева Әдилә туплады



# Туфанлы мизгелләр...

*Кулымда Туфан Миңнуллинның* ***"Сайланма әсәрләре"нең 10нчы томы****. 2002нче елда басылып чыккан бу китапка әңгәмәләр, мәкаләләр тупланган.Сезнең өчен бу тормышта иң кадерлесе, иң газизе, иң матуры, иң ямьсезе, иң мәзәге, иң гаҗәбе нәрсә? дигән сорауга Туфан Миңнуллин: Эшләнгән хәерле эш,- дип җавап бирә. Драматургның эшләнгән хәерле эшләре бик*

*күп. Аның турында бары матур мизгелләр генә туа...*

***Хөсәенова Айзилә – 8нче сыйныф укучысы***



















Елма

## Сынамышлар

***

Әгәр май башларында син йокыдан уянганда кояш төшлеккә күтәрелгән булса, ул елны бакчаңда алабута уңар.

***

Әгәр дә Казан трамвайларында авызыңны ачып йөрсәң, кесәңдәге акчаңнан җилләр исәр.

**Диалоглар**

***

-Татар авылы микән бу?

- Кәнишне инде. Әнә ич “Дом культуры” дип язып куйганнар.

***

- Нигә ашамыйсың? Ачыктым, эчемдә бүреләр улый, дигән иден.
- Бүреләр әчегән кәбестә шулпасы эчмиләр шул.

***

- Этенне кунак итимме?
- Ничек итеп?
- Үземә өрдеттерәм.

***


- Улым, печән чабар чак җитте.
- Мин печән ашамыйм. Кем ашый, шул чапсын

**Реклама**

“Ока” машинасы алыгыз. Этеп йөрү өчен искикеч җиңел автомобиль.

Материал Туфан Миңнуллинның “Насыйбулла боткасы” китабыннан алынды. Материалларны туплаучы – 7нче сыйныф укучысы - Хафизова Инзилә

**Татар кешесе! Бел! Син сөйләшкән тел дистәләгән гасырлар буенча чарланып, иң камил телләр дәрәҗәсенә күтәрелгән. Синең телеңдә ккатлаулы фәнни хезмәтләр дә, илаһи төшенчәләр дә , гүзәл әдәби әсәрләр дә язылган. Аны хөрмәт ит, сакла һәм үстер!**



**Татар кешесе! Укы! Гыйлемле-белемле**

# Туфан Миңнуллин

**ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ**

май, 2023нче ел

***“Бакый Зиятдинов исемендәге Карадуган гимназиясе” укучылары газетасы***

Газета ай саен, 2011нче елдан башлап чыгарыла

Адрес: Карадуган авылы,
Себер таркты урамы, 51 йорт,
Тел.:88436832119

Баш мөхәррир: Гарифуллина Э.М.
Мөхәррир : Хөсәенова Айзилә
Корректорлар: Нуриева М., Лотфуллина И.

Корреспондентлар: Хафизова И., Нургалиева Ә., Кәлимуллина З., Галиәхмәтова Р.
Дизайнер:Сабитов .А.
Компьютерда җыючылар: Файзрахманов Салават, Сөнгатуллин Илгиз



Ссылка на газету

https://edu.tatar.ru/upload/storage/org540/files/%D0%93%D0%B8%D0%BC%D0%BD%D0%B0%D0%B7%D0%B8%D1%8F%20%D1%81%D1%83%D0%BB%D1%8B%D1%88%D1%8B%20%D0%B3%D0%B0%D0%B7%D0%B5%D1%82%D0%B0%D1%81%D1%8B%202023%D0%BD%D1%87%D0%B5%20%D0%B5%D0%BB%20%D0%BC%D0%B0%D0%B9.pdf

**Наша газета “Гимназия сулышы” получила призовое место в республиканском конкурсе “Безнең сүз”**



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНЫҢ
МӘГАРИФ, МӘДӘНИЯТ, ФӘН ҺӘМ МИЛЛИ МӘСЬӘЛӘЛӘР КОМИТЕТЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
КАЗАН ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫНЫҢ МӘГАРИФ ИДАРӘСЕ

КАЗАН ШӘҺӘРЕ МӘСКӘҮ РАЙОНЫ
«Ф.Г.АИТОВА ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ
12 НЧЕ ГИМНАЗИЯ» МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

ДИПЛОМ

ХАЛЫК ЯЗУЧЫСЫ, КҮРЕНЕКЛЕ ДРАМАТУРГ, ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ
ТУФАН МИҢНУЛЛИН исемендәге
VIII РЕСПУБЛИКА
КОНФЕРЕНЦИЯСЕНЕҢ

ЖУРНАЛИСТИКА

“Кызыл тышлы дәфтәрдән” номинациясенең

“Безнең сүз” балалар матбугаты бәйгесендә

ПРИЗЕР

*Балтач районы «Бакый Зыятдинов исемендәге*

*Карадуган гимназия»сенең 5, 7, 8, 9нчы сыйныф укучылары*

5нче сыйныф укучысы - Корбанова Зилә

*“Гимназия сулышы” газетасы*

*Җитәкчеләре: Гарифуллина Эльмира Мәсхүт кызы*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЫ УРЫНБАСАРЫ М.З. ЗАКИРОВА

## Другие публикации нашей газеты

